БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 09 2020 ел № 289

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 мартындагы 47-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктчасы белән тулыландырырга:

Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар мондый оешмаларны оештыручы тарафыннан федераль бюджетның, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре һәм Россия Федерациясе законнарында каралган финанслауның башка чыганаклары исәбеннән, кайнар эчемлекне исәпкә алмаганда, кайнар ашамлык булуны күздә тоткан түләүсез кайнар ризык белән тәэмин ителә.

2. Карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына

(социаль мәсьәләләр буенча) һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов